**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МАКАРОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422602 , РТ, Лаишевский район, село Ташкирмень, ул.Мира, д.40
тел: 8-(84378) -4-85-25
факс: 8-(84378) -4-85-25

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МАКАРОВКА АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422602, РТ, Лаеш районы, Ташкирмэн авылы , Тынычлык урамы, 40 нче йорт,
тел: 8-(84378) -4-85-25
факс: 8-(84378) -4-85-25

---

**2020елның 4 августы** **8 номер**

# КАРАР

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Макаровка авыл җирлеге Советына депутатлыкка кандидатларның, Макаровка авыл җирлегенең 1735 номерлы сайлау участогы территориясендә басма агитация материалларын урнаштыру өчен махсус урыннар бүлеп бирү турында.**

Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Макаровка авыл җирлеге Советына депутатлыкка кандидатлар өчен 1735 номерлы сайлау участогы территориясендә басма агитация материаллары урнаштыру өчен махсус урыннар бүлеп бирү турында Татарстан Республикасы Лаеш районы территориаль сайлау комиссиясе тәкъдимен карап тикшергәннән соң, «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законның 54 статьясындагы 7 пунктына, Татарстан Республикасы Сайлау Кодексының 64 статьясындагы 8 пунктына таянып, карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Макаровка авыл җирлеге Советына депутатлыкка кандидатларның басма агитация материалларын 1735 номерлы сайлау участогы территориясендә урнаштыру урыны итеп Татарстан Республикасы, Лаеш муниципаль районы, Макаровка авылы, Тынычлык ур., адресы буенча урнашкан мәгълүмати стендны билгеләргә.

2. Карарны Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының территория сайлау комиссиясенә җибәрергә.

3 .Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

**Макаровка авыл җирлеге**
**башкарма комитеты җитәкчесе** **В.В.Кормачев**